РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ТАШКИЧУЙСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГОРАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ТАШКИЧҮ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

423959, Республика Татарстан,
Ютазинский район, деревня Малые Уруссу,
улица Советская, дом 21А
тел. 85593 4-23-10, факс 85593 4-23-40

423959, Татарстан Республикасы,
Ютазы Районы, Кече Урыссу авылы,
Совет урамы, 21А йорты.
эл.адрес Tash.Utz@ tatar.ru

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

22 январь 2024 ел № 1

**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль закон, 2004 елның 24 мартындагы «Җирле референдум турында»гы 23-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Ташкичү авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә,

2023 елның 24 октябрендәге Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Биектау торак пунктының халык җыенының 1 санлы карары;

2023 елның 25 октябрендәге Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлегенең Хөррият торак пунктында халык җыенының 2 санлы карары;

2023 елның 26 октябрендәге Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлегенең Ташкичү торак пунктында халык җыенының 3 санлы карары;

2023 елның 27 октябрендәге Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлегенең Кече Урыссу торак пунктында халык җыенының 4 санлы карарларын гамәлгә ашыру максатларында,

Ташкичү авыл җирлеге башкарма комитеты к а р а р итте:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлегендә гражданнарның үзара салымын җыю тәртибен расларга.
2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (http:pravo.tatarstan.ru).
3. Әлеге карарның үтәлешен үз контролемдә тотам.

Ташкичү авыл җирлеге башлыгы Р.К.Вәлиев

Ташкичү авыл җирлеге Башкарма комитетының
2024 елның 22 январе
1 санлы карарына
1 кушымта

**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю тәртибе**

1. Әлеге тәртип Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән 18 яше тулган гражданнар, Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм аларның тол калган тормыш иптәшләре, хәрби хезмәттә булучылардан тыш, гражданнар җыенында катнашу-катнашмауларына һәм тавыш бирүдә алар тарафыннан белдерелгән мөнәсәбәтләренә бәйсез рәвештә, 2024 елның 1 февраленнән 2024 елның 30 мартына кадәр үзара салым акчалары түләүне башкарыла.

3. Җитди сәбәпләр булган очракта, ә аларга түбәндәгеләр керә ала:

а) торган урын буенча озак яшәмәү,

б) авыру,

гражданнарга гариза нигезендә түләү кертүне өч айдан да артмаган вакытка кичектерергә мөмкин.

4. Бер тапкыр түләү турында хәбәрнамә (искәртү) бланкы гражданнарга мәгълүмат стендларында бастырып чыгару һәм Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында халыкка хәбәр итү юлы белән, шулай ук имзаны тапшыру яисә почта элемтәсе аша юллау юлы белән җиткерелә.

Хәбәрнамәдә (искәртүдә) гражданнарның үзара салым акчаларын күчерүнең түләү реквизитлары, бер тапкыр бирелә торган түләү суммасы, аны түләү вакыты булырга тиеш.

5. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акчалар Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлегенең шәхси счетына керә.

6. Түләүләр физик затлар йөкләмәсе буенча исәп-хисап ясау хокукына ия булган оешмалар аша почта күчермәләрен (исәп-хисап оешмалары) гамәлгә ашыру юлы белән башкарыла.

7. Түләү фактын раслый торган касса ордерының квитанциясе, чек-ордер, түләү фактын раслаучы башка документлар.

8. Билгеләнгән вакытка кертелмәгән гражданнарның үзара салымы акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.

Ташкичү авыл җирлеге Башкарма комитетының
2024 елның 22 январе
1 санлы карарына
2 кушымта

Ташкичү авыл җирлеге бюджетына
үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында
____ санлы
ХӘБӘРНАМӘ (ИСКӘРТҮ)

Түләүченең Ф.И.А. ____________________________________________________
Адрес: ______________________________________________________________
Халык җыены карары нигезендә торак пунктта______________________Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге 2024 елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча сезгә 2024 елның 30 мартына кадәр халык җыены чараларын тормышка ашыру өчен бер тапкыр түләүне түбәндәге реквизитлар буенча башкарырга кирәк:

Банк получателя
БИК

Алучы
Счет номеры №
ИНН КПП
КБК
ОКТМО
Билгеләнгән түләү: **2024 ел өчен Ташкичү авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчасы.**

Җитәкче _____________________________________________________
П.У. (имза) (имзаны раслау)

- - - - - - - - - - - - - - - - - - кисү линиясе - - - - - - - - - - - - - - -

Ташкичү авыл җирлеге бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында
№ __________________ санлы хәбәрнамә (искәртү)
(муниципаль берәмлек исеме)
_________________ сум күләмендә
Түләүченең Ф.И.А. ____________________________________________________
Адрес: ______________________________________________________________
«__» ________________ 20__ елны ___________________________________ алдым
(түләүченең имзасы)

*Искәрмә. Мәгълүмат түләүчегә шәхси тапшырылган очракта, аерым корешок тутырыла һәм Ташкичү авыл җирлеге Башкарма комитетында кала.*